| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ЗАРЕЧЕНСК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2021 нче ел Яңа Зареченск авылы № 41

Совет карары проекты турында
Яңа Зареченск авыл җирлеге
Баулы муниципаль районы
«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар
план чорына Яңа Зареченск
авыл җирлеге бюджеты турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Яңа Зареченск авыл җирлегендә 2020 елның 18 мартындагы 137 номерлы ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты турында»гы Карары проектын (1 нче кушымта) хупларга һәм фикер алышуга чыгарырга.

2. №1 кушымта нигезендә карар проектын беренче укылышта кабул итәргә.

3. Раслау:

- Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты турында» гы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуларда катнашу тәртибе (2 нче кушымта);

- Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибе (3 нче кушымта).

4. Әлеге карарны, Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты турында» Карары проектын Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (http://www.bavly.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты турында» гы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

1. Зәбирова Әлфия Рафаил кызы – эшче төркем рәисе.

2. Низамова Резедә Роберт кызы – Яңа Зареченск авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре.

3. Шәрифуллина Альбина Фатыйх кызы – эшче төркем әгъзасы.

4. Гатина Зилә Минтаһир кызы – эшче төркем әгъзасы.

5. Никулина Клавдия Николаевна – эшче төркем әгъзасы.

6. 2021 елның 22 ноябрендә 15.00 сәгатьтә Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында (Татарстан Республикасы, Баулы муниципаль районы, Яңа Зареченск поселогы, Вахитов урамы, 15 нче йорт) Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджет турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

7. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советы депутатларының һәм гражданнарның «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты турында»гы карар проекты буенча тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Баулы муниципаль районы Яңа Зареченск авыл җирлеге Советына карауга чыгарырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Яңа Зареченск авыл җирлеге Советының «2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты турында»гы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркемгә йөкләргә.

Җирлек башлыгы, Яңа Зареченск
авыл җирлеге Советы Рәисе А.Р. Зәбирова